ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 08 2019 г. № 187

Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының саклынышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру муниципаль функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 28 мартындагы 53 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының 2017 елның 28 мартындагы 53 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Түбән Кама шәһәре» муниципаль берәмлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру муниципаль функциясен үтәүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.1. пунктында «(алга таба – муниципаль контроль)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 1.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Әлеге Регламентта кулланыла торган төшенчәләр «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – «2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон»)» каралган мәгънәләрдә кулланыла;

1.3. 1.7. пунктының 1 абзацында «күрсәтелгән таләпләр» сүзләреннән соң «юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара бәйләнешсез гамәлгә ашырыла торган контроль чаралары» сүзләрен өстәргә;

1.4. 1.7. пунктының 3 абзацында «(әлеге регламентка 2-нче кушымта)» сүзләрен төшереп калдырырга»;

1.5. 1.9.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.9.1. Муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары, тикшерүне үткәргәндә, 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьяның 1 пунктында, 18 статьясында каралган вазыйфаларны, шулай ук 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясында каралган чикләүләрне үтәргә тиеш. Тикшерү үткәргәндә юридик затның, шәхси эшмәкәрнең хокуклары 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясында билгеләнгән.»;

1.6. 3.1.4. пунктның 3 пунктчасында «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан тиешле өлкәдә федераль башкарма хакимият органы» сүзләрен «тиешле эшчәнлек өлкәсендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 3.2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.1. 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешендә каралган очраклар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора.»;

1.8. 3.4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Тикшерү Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле вәкиле тарафыннан федераль башкарма хакимият органы билгеләгән форма буенча расланган муниципаль контроль органы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

1.9. 3.7.1. пунктына «, әлеге регламентка 3-нче кушымтада билгеләнгән форма буенча» сүзләрен өстәргә;

1.10. 1.7. пунктының 2 абзацын, 1.8, 1.9.2, 1.9.3, 1.10, 1.10.1, 3.2.2, 3.3.1, 3.4.2, пунктларын, 1-нче һәм 2-нче кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Житәкче Д.И. Баландин

ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ
ДОКУМЕНТЛАР ӨЧЕН
ИНН 1651044881